КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 23 август г.Казань № 627

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2025 ел, 8 апрель, 207 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2025 ел, 8 апрель, 207 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «11 053 кв.метр мәйданлы, 16:28:080701:15 кадастр номерлы җир кишәрлеген» сүзләрен «11 053 кв.метр мәйданлы, 16:28:080701:15 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 2 249 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында «М-7 – «Волга» – Яңа Александровка – Тулыбай», 5+978 км автомобиль юлындагы Ашбула елгасы күперен реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2020 елның 19 маендагы 468 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен башкаруны;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган җир кишәрлеге өчен түләүләр күләмен билгеләүне.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин